**СОВЕТ ДУБЪЯЗСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422720, Республика Татарстан, Высокогорский район, с. Дубъязы, ул.Ленина, 28

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ДӨБЪЯЗ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422720, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Дөбъяз авылы, Ленин ур., 28

Тел./факс: +7(84365) 612-97, e-mail: Dub.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**7 август 2020 г.** **№ 168**

**«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбъяз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Дөбъяз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбъяз авыл җирлеге Советы,

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбъяз авыл җирлеге Советының 2019 елның 13 декабрендәге 150 нче номерлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбъяз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяны түбәндәге эчтәлектәге 20 пункт белән тулыландырырга:

«20) Россия Федерациясе гражданлык законнары нигезендә үз белдеге белән төзелгән корылманы җимерү турында карар кабул итү, рөхсәтсез корылманы җимерү яисә аны, җир белән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрендә, территорияне планлаштыру документларында, яисә федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына мәҗбүри таләпләргә туры китереп, капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең чик параметрларына туры китерү турында карар кабул итү.»;

2) 31 статьяның 1 пунктында «7 депутаттан» сүзләрен «10 депутаттан» сүзләре белән алыштырырга.

3) 51 статьяның 5 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 8 абзац белән тулыландырырга:

«-Россия Федерациясе гражданлык законнары нигезендә үз белдеге белән төзелгән корылманы җимерү турында карар кабул итү, рөхсәтсез корылманы җимерү яисә аны, җир белән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрендә,

территорияне планлаштыру документларында, яисә федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына мәҗбүри таләпләргә туры китереп, капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең чик параметрларына туры китерү турында карар кабул итә .»;

4) 66 статьяны түбәндәге эчтәлектәге 4 пункт белән тулыландырырга:

«4. Үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә гамәлгә ашыру өчен җирлек Советы депутатына эш урынын (вазыйфасын) саклап калу гарантияләнә, аның дәвамлылыгы Татарстан Республикасы законы нигезендә муниципаль берәмлек уставында билгеләнә һәм җыелма рәвештә аена ике көннән ким һәм 6 эш көненнән күбрәк була алмый.»;

Түбәндәге эчтәлектәге 74.1 статья белән тулыландырырга:

«74.1 статья. Якын-тирәдәге территорияләрнең чикләрен билгеләү тәртибе

1. Якын-тирәдәге территорияләрнең чикләре, әгәр шундый җир кишәрлеге төзелгән булса, бинага, төзелешкә, корылмага, җир кишәрлегенә тоташа торган (уртак чиге булган) гомуми файдаланудагы территорияләргә карата билгеләнә.

2. Якын-тирәдәге территорияләрнең чикләре гамәлдәге төзелештә биналарның, корылмаларның, җир кишәрлекләренең урнашуына, аларның рөхсәт ителгән файдалану төренә һәм фактта билгеләнешенә, аларның мәйданына һәм күрсәтелгән гомуми чикнең озынлыгына, якындагы территорияләрнең максималь һәм минималь мәйданына бәйле рәвештә билгеләнә.

3. Муниципаль берәмлек территориясендәге якын-тирә территориянең максималь һәм минималь мәйданы төзекләндерү кагыйдәләре белән билгеләнә. Якын-тирәдәге территорияләрнең максималь һәм минималь мәйданы якындагы территорияләрнең төрле төрләре өчен дифференциацияләнгән рәвештә, шулай ук гамәлдәге төзелештәге биналарның, төзелешләрнең, корылмаларның, җир кишәрлекләренең, алардан рөхсәт ителгән файдалану төренең һәм факттагы билгеләнешенең урнашуына, аларның мәйданына, әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән гомуми чикнең сузылуына, башка әһәмиятле факторларга бәйле рәвештә билгеләнергә мөмкин. Якын-тирәдәге территориянең максималь мәйданы якындагы территориянең минималь мәйданыннан утыз процентка артык була алмый.

4. Якын-тирәдәге территорияләрнең чикләрен билгеләүнең башка мәсьәләләре Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан җайга салына.».

5) 88 статьяның 3 пунктын төшереп калдырырга;

6) 93 статьяның 5 пунктын төшереп калдырырга;

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбъяз авыл җирлеге Башлыгына әлеге Карарны Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә әлеге Карар кабул ителгән көннән 15 (унбиш) көн эчендә дәүләт теркәвенә җибәрүне йөкләргә.

3. Әлеге карар дәүләт теркәве узганнан соң Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбъяз авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Биектау районы, Дөбъяз авылы, Ленин ур., 1 йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча рәсми рәвештә басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) мизгелдән үз көченә керә.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы А.С.Низамов